КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 17 март г.Казань № 139

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе мәсьәләләре» 2005 ел, 5 август, 391 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип тану хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе мәсьәләләре» 2005 ел, 5 август, 391 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 5 сентябрь, 431 нче; 2005 ел, 29 декабрь, 649 нчы; 2006 ел, 1 март, 90 нчы; 2006 ел,

14 август, 415 нче; 2008 ел, 5 март, 137 нче; 2008 ел, 5 май, 289 нчы; 2009 ел, 10 июнь, 383 нче; 2010 ел, 19 июль, 574 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 7 ноябрь, 921 нче; 2011 ел, 25 ноябрь, 965 нче; 2012 ел, 31 август, 742 нче; 2013 ел, 19 гыйнвар, 21 нче; 2013 ел, 31 октябрь, 824 нче; 2014 ел, 26 февраль, 123 нче; 2015 ел, 2 октябрь, 730 нчы; 2016 ел, 26 август, 593 нче; 2018 ел, 8 август, 644 нче; 2018 ел, 31 октябрь, 976 нчы; 2018 ел, 18 декабрь, 1159 нчы, 2018 ел, 29 декабрь, 1299 нчы, 2020 ел, 17 февраль, 120 нче, 2020 ел, 15 апрель, 288 нче; 2020 ел, 24 август, 724 нче; 2020 ел, 3 ноябрь, 987 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 һәм 3.2 пунктлары нигезендә Татарстан Республикасының Дәүләт алкоголь инспекциясе түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияли (авыл хуҗалыгы җитештерүчеләре тарафыннан җитештерелгән шәраб продукциясен ваклап сатуны лицензияләүдән тыш);

алкогольле һәм спиртлы продукцияне ваклап сату күләме, шәраб продукциясен җитештерү өчен җыелган виноград күләме турында декларацияләр кабул итә;

алкогольле һәм спиртлы продукцияне ваклап сату өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыра;

Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары өчен билгеләнгән компетенция чикләрендә оешмаларның һәм юридик зат булып оешмаган индивидуаль эшмәкәрләрнең алкогольле һәм спиртлы продукцияне ваклап сату өлкәсендә дәүләт контролен тәэмин итүгә бәйле булган хисаплар, мәгълүматлар, декларацияләр, башка документларны үз вакытында һәм дөрес итеп бирүне тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыруны тәэмин итә;

этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерү һәм әйләнештә йөртү буенча уртак программалар эшләү һәм аларны гамәлгә ашыру турында тәкъдимнәр кертә;

законсыз әйләнештә йөртүдән алынган йә конфискацияләнгән, матди дәлилләр йә административ хокук бозу предметлары булган этил спиртын, алкогольле һәм спиртлы продукцияне исәпкә ала;

тиешле чаралар күрү өчен этил спирты, спиртлы һәм алкогольле продукция җитештерү, әйләнештә йөртү һәм аларның сыйфаты өлкәсендә, шулай ук кулланучылар базары һәм кулланучылар хокукларын яклау өлкәсендә ачыкланган бозулар турындагы материалларны контроль (күзәтчелек), хокук саклау һәм суд органнарына билгеләнгән тәртиптә кертә;

кулланучылар хокукларын яклау буенча дәгъва итү эшчәнлеген оештыра һәм гамәлгә ашыра;

кулланучылар базарында хезмәт күрсәтүләрне ихтыярый сертификацияләү эшен оештыра;

этил спирты, спиртлы һәм алкогольле продукция җитештерү, әйләнештә йөртү һәм аларның сыйфаты өлкәсендә, шулай ук кулланучылар базары өлкәсендә

Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары проектларын, контроль буенча тәкъдимнәр эшләүдә катнаша;

азык-төлек продуктларының сыйфатын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итүнең республика программаларын эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда катнаша;

Татарстан Республикасы предприятиеләре продукциясен сатуны арттыруга юнәлдерелгән чараларны эшләү һәм гамәлгә ашыру эшчәнлеген башкара;

Татарстан Республикасының эчке базарында халык куллану товарларының бәяләре һәм ассортименты мониторингын үткәрә;

кулланучылар базарына сыйфатсыз һәм куркыныч азык-төлек продуктлары, материаллар һәм әйберләр керүне булдырмау чараларын эшләүдә катнаша;

федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә дәүләт ихтыяҗлары һәм Татарстан Республикасының Дәүләт алкоголь инспекциясе ихтыяҗлары өчен товарлар кайтартуга, хезмәтләр күрсәтүгә, эшләр башкаруга заказлар урнаштыра һәм дәүләт контрактларын төзи;

алкогольле һәм спиртлы продукцияне ваклап сату өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча норматив хокукый актлар эшли һәм аларны үз компетенциясе чикләрендә раслый;

этил спирты, спиртлы һәм алкогольле продукция җитештерү һәм (яки) әйләнештә йөртү өлкәсенә караган, шулай ук кулланучылар базары өлкәсендә алар буенча мәгълүматлар базасын төзүдә һәм үстерүдә катнаша;

Татарстан Республикасының Дәүләт алкоголь инспекциясе компетенциясенә кагылышлы мәсьәләләр буенча законнар куллану практикасын гомумиләштерә, аны камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерли һәм аларны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертә;

кулланучыларның хокукларын яклау чараларын һәм Татарстан Республикасының Дәүләт алкоголь инспекциясе компетенциясенә кертелгән башка мәсьәләләрне гамәлгә ашыру барышын массакүләм мәгълүмат чараларында даими яктыртуны тәэмин итә;

контроль (күзәтчелек) һәм хокук саклау органнары белән үзара хезмәттәшлекне оештыра;

ачыкланган бозуларның сәбәпләрен анализлый һәм, дәүләт хакимияте башкарма органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар белән берлектә, аларны кисәтү һәм бетерү буенча чаралар күрә;

Татарстан Республикасының Дәүләт алкоголь инспекциясе компетенциясенә кагылышлы мәсьәләләр буенча хатлар, гаризалар, шикаятьләрне, гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карап тикшерә;

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең, эшләре Татарстан Республикасының Дәүләт алкоголь инспекциясе эшчәнлегенә бәйле булган яки аны алып бару өлкәсенә караган оешмаларның мобилизацион әзерлеген һәм мобилизациясен оештыра һәм тәэмин итә, шулай ук бу чараларның методик тәэмин ителешен гамәлгә ашыра;

үз компетенциясе нигезендә федераль башкарма хакимият органнары, аларның территориаль органнары, Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимияте органнары, башка Россия һәм чит ил органнары һәм оешмалары белән төзелгән

шартнамәләр, килешүләр һәм башка гавами-хокукый характердагы актлар реестрын алып бара;

ел саен, 1 февральгә кадәр, Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру буенча махсус дәүләт органына коррупциягә каршы сәясәт чараларын гамәлгә ашыру турында хисап кертә;

Татарстан Республикасының ведомство буйсынуындагы дәүләт казна, бюджет һәм автоном учреждениеләрен (алга таба – учреждениеләр) гамәлгә куючы функция-ләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра, шул исәптән:

учреждениеләр төзү, үзгәртеп оештыру, аларның типларын үзгәртү, бетерү турындагы карарлар проектларын әзерли, аларның уставларын раслый һәм аларга үзгәрешләр кертә;

учреждениеләргә учреждениенең уставында каралган төп эшчәнлек төрләре нигезендә юридик һәм физик затларга дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыра һәм раслый;

учреждениеләрне гамәлгә куючының башка функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра;

учреждениеләр эшчәнлегенең дәүләт учреждениеләре эшчәнлеген бәяләүнең билгеләнгән критерийларына туры килүен бәяли;

Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган Россия Федерациясендә хокук куллану мониторингын гамәлгә ашыру методикасы нигезендә Татарстан Республикасында хокук куллану мониторингын үз компетенциясе чикләрендә гамәлгә ашыра;

алкогольле һәм спиртлы продукцияне ваклап сату күләме турындагы декларацияләрдәге мәгълүматларны этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерү һәм әйләнештә йөртү өлкәсендә тикшерүдә тоту (күзәтчелек итү) буенча вәкаләтле федераль башкарма хакимият органына электрон рәвештә җибәрә;

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы белән Татарстан Республикасының Дәүләт алкоголь инспекциясе компетенциясенә кертелгән административ хокук бозулар турындагы делоларны карап тикшерә;

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы нигезендә алкогольле һәм спиртлы продукцияне ваклап сату өлкәсендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүне башкара;

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының $20.6^1$ статьясында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүне башкара;

ведомство буйсынуындагы оешмаларда хезмәт законнарының һәм хезмәт хокукы нормалары булган башка норматив хокукый актларның үтәлешен ведомство тикшерүендә тотуны гамәлгә ашыра.»;

4.1 пунктта:

бишенче абзацта «Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы;» сүзләрен «этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерү һәм аларны әйләнештә йөртү өлкәсендә тикшерүдә тоту (күзәтчелек итү) буенча вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы;» сүзләренә алмаштырырга;

егерме беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«контроль функцияләрен гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Татарстан таможнясы, Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәте идарәсе, Федераль монополиягә каршы хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы, Техник җайга салу һәм метрология федераль агентлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсенә караган Татарстан Республикасында территориаль бүлеге (инспекциясе), Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Дәүләт мөлкәте белән идарә итү федераль агентлыгының Татарстан Республикасында һәм Ульяновск өлкәсендә төбәкара территориаль идарәсе, Федераль суд приставлары хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе белән үзара хезмәттәшлек итәргә;».

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе мәсьәләләре» 2005 ел, 5 август, 391 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе турында нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында» 2020 ел, 15 апрель, 288 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе мәсьәләләре» 2005 ел, 5 август, 391 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе турында нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 15 апрель, 288 нче карарына үзгәреш кертү турында» 2021 ел, 1 февраль, 46 нчы.

3. Бу карарның 1 пунктындагы кырыгынчы абзацы 2021 елның 31 декабренә кадәр (31 декабрьне кертеп) гамәлдә була дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин